| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14 ноябрь 2023 ел № 218

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының территориаль планлаштыру Схемасына, аларга карата генераль планны әзерләү зарурлыгы булмау турында карар кабул ителгән авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан торак пунктлар чикләре турындагы белешмәләр белән тулыландыру өлешендә үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 20, 21 статьялары, «Россия Федерациясе җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының территориаль планлаштыру Схемасына, алпарга карата генераль планны әзерләү зарурлыгы булмау турында карар кабул ителгән авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан торак пунктлар чикләре турындагы белешмәләр белән тулыландыру өлешендә үзгәрешләр кертү проектына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 12 октябрендәге 10-53/12638 номерлы бәяләмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар бирде:

1. Балтач район Советының 2013 елның 27 апрелендәге 162 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының территориаль планлаштыру Схемасына, аларга карата генераль планны әзерләү зарурлыгы булмау турында карар кабул ителгән авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан торак пунктлар чикләре турындагы белешмәләр белән тулыландыру өлешендә (2019 елның 31 маендагы 187 номерлы, 2020 елның 29 маендагы 251номерлы, 2022 елның 15 декабрендәге 163 номерлы үзгәрешләр белән) кушымталар нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының территориаль планлаштыру Схемасына, аларга карата генераль планны әзерләү зарурлыгы булмау турында карар кабул ителгән авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан торак пунктлар чикләре турындагы белешмәләр белән тулылындыру өлешендә үзгәрешләр кертүне раслау турындагы карарны территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасына кертүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл хуҗалыгы, җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм фермер хуҗалыкларына ярдәм күрсәтү буенча даими комиссиягә тапшырырга.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин

Татарстан Республикасы
Балтач район Советының
2023 елның «14» ноябреннән
217 номерлы карарына
кушымта

Чикләр турындагы өстәмә белешмәләр белән тулыландыру өлешенә үзгәрешләр кертелә торган торак пунктлар исемлеге

1)Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Борбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Алан авылы

2) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Нөнәгәр авыл җирлеге » муниципаль берәмлегенең Комаров-Завод авылы

3) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Югары Субаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Көшкәтбаш авылы

4)Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Нөнәгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Нөнәгәр авылы

5) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Борнак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иске Торҗа авылы